**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2018 елның 28 февраленнән № 482

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомумбелем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчалары) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү” муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын яңа редакциядә раслау турында**

Россия Федерациясе Конституциясенә, 2003 елның 6 октябреннән №131 (2015 елның 30 мартына үзгәрешләр белән) “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга, 2010 елның 27 июленнән №210-ФЗ (2014 елның 31 декабренә үзгәрешләр белән) “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законга, 2012 елның 29 декабреннән №273-ФЗ “Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 1 мартыннан №165 “Татарстан Республикасында мәгариф системасын үстерү турында»гы карарына, ТР мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 10 мартыннан № под - 1389/15 боерыгы белән расланган “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомумбелем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү” муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентның якынча формасына үзгәрешләр кертү турында”гы Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2018 елның 26 декабреннән № под 1975-18 боерыгына ярашлы төстә **карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомумбелем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчалары) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү” муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын яңа редакциядә расларга.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 7 августыннан №2518 Татарстан Республикасы

Лаеш муниципаль районында “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомумбелем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчалары) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү” муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын яңа редакциядә раслау турында”гы карарын көчен югалткан дип табарга.

3.” Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы мәгариф идарәсе”МКУ начальнигы Г.Х.Шәриповага әлеге Административ регламентның үтәлешен тәэмин итәргә.

4.Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).

5.Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Г.Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **М.В.Фадеев**